Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге
Ивановка авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 21 ноябрь № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Ивановка авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Ивановка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Зиратка, Нагорная урамы буенча (3нче йорттан 10нчы йортка кадәр) һәм Заречная урамына кадәр (17нче номерлы йортка кадәр) юлларга вак таш җәю;
- Ивановка авылында (Үзәк, Октябрь, Яшьлек, Заречная, Нагорный, Энтузиастлар, Родничная, Мәктәп тыкрыгы) юлларны кардан чистарту .

II. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
-үлән чабу (Ивановка авылында гомуми файдаланудагы территорияләрдә үлән чабу хезмәтләре күрсәтү; ягулык-майлау материалларына чыгымнар).

III. Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру:
-Ивановка авылының Яшьлек урамы буенча балалар спорт комплексы сатып алу һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Ивановка авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга. 4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П.Бодряева